**07.11.2023 елның 2 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге составына керүче Бөрбаш Сәрдегәне авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**22 март 2024 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегенең Бөрбаш Сәрдегәне торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Бөрбаш авыл җирлеге составына керүче Бөрбаш Сәрдегәне авылында гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

- 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

- Бөрбаш Сәрдегәне торак пунктындагы Г.Зарипов урамындагы асфальт-бетон юл түшәмәсен норматив хәлгә китерү».

2. Халык җыены нәтиҗәләрен Бөрбаш авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль, берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Галимуллин